РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2019 елның 14 марты 12нче номерлы**

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты вәкаләтләре өлешен тапшыру турында 2018 елның 28 ноябрендәге Килешүгә үзгәрешләр кертү хакында Килешүне раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. 2018 елның 28 ноябрендә кабул ителгән Түбән Кама шәһәр Советының 46 нчы номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты вәкаләтләре өлешен тапшыру турында 2018 елның 28 ноябрендәге Килешүгә үзгәрешләр кертү хакында Килешүне расларга.

2. Түбән Кама муниципаль районы Советына тәкъдим итәргә:

2.1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты вәкаләтләре өлешен тапшыру турында 2018 елның 28 ноябрендәге Килешүгә үзгәрешләр кертү хакында Килешүне расларга.

2.2. Түбән Кама муниципаль районы җирле үзидарә органнары үз компетенциясе чикләрендә Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты вәкаләтләре өлешен тапшыру турындагы Килешүгә үзгәрешләр кертү турындагы Килешүне гамәлгә ашыру өчен норматив һәм норматив булмаган хокукый актлар гамәлгә кертергә һәм кулланырга хокуклы икәнлеген билгеләргә.

3. Әлеге карарны гаммәви мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәре Мэры урынбасары Э.Р.Долотказинага йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты вәкаләтләре өлешен тапшыру турында 2018 елның 28 ноябрендәге Килешүгә үзгәрешләр кертү хакында

Килешү

Түбән Кама шәһәре 2019 елның 14 марты

Алга таба «Шәһәр башкарма комитеты» дип аталучы Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты, шәһәр Уставы нигезендә эш итүче җитәкче Баландин Денис Иванович йөзендә, бер яктан, һәм алга таба «Район Башкарма комитеты» дип аталучы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты, район Уставы нигезендә эш итүче җитәкче Сәйфетдинов Айдар Габдуллаҗан улы йөзендә, икенче яктан, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешенә таянып, түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр:

## 1. Килешү предметы

Әлеге Килешүгә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты вәкаләтләре өлешен тапшыру турында 2018 елның 28 ноябрендәге Килешүгә Яклар түбәндәге үзгәрешләр кертергә карар бирделәр:

Килешүнең 1.2 пунктында

«билгеләнгән тәртиптә бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану» сүзләрен «бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану» сүзләренә алмаштырырга;

«торак биналарны үзгәртеп коруны һәм үзгәртеп планлаштыруны килештерү» сүзләрен «күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп коруны һәм үзгәртеп планлаштыруны килештерү» сүзләренә алмаштырырга;

«-җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү» сүзләрен өстәргә.

## 2. Йомгаклау нигезләмәләре

Әлеге Килешү Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре Башкарма

комитеты вәкаләтләре өлешен тапшыру турында 2018 елның 28 ноябрендәге килешүгә үзгәрешләр кертү турында Килешүне раслау турында Түбән Кама шәһәр Советы һәм Түбән Кама муниципаль районы Советы карарлары үз көченә кергән көннән үз көченә керә.

Әлеге карарның 1 пунктындагы 3 абзацның гамәлдә булуы 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла. Әлеге карарның 1 пунктындагы 4 абзацның гамәлдә булуы 2019 елның 8 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Әлеге Килешү 2 (ике) нөсхәдә төзелгән, бертигез юридик көчкә ия һәр Якка берешәр нөсхә.

Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитеты
Адрес: 423570, Түбән Кама шәһәре,
Төзүчеләр проспекты, 12

Татарстан РеспубликасыТүбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе

______________А.Г. Сәйфетдинов

Түбән Кама шәһәре

Башкарма комитеты

Адрес: 423570, Түбән Кама шәһәре,
Төзүчеләр проспекты, 12

Татарстан РеспубликасыТүбән Кама шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе

____________ Д.И. Баландин